СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*11 октябрь, 1997ел.*
*ШИМБӘ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 115 (8127)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## «Уңыш - 97» бәйрәмендә катнашучыларга кайнар сәлам!

***Барыгызны да 12 нче октябрь көнне булачак бәйрәмгә чакырабыз. Ул иртәнге 9 сәгатьтә аэропорт мәйданында башлана.***

## Ил табынында быел Октябрь икмәге 86 мең тонна тәшкил итте.

## Аның 55 мең тоннасы -ашамлык бодае

**«Алга» КХАсыннан Рәшит Насыйбуллин «Дон - 1500» комбайнында 40150 центнер ашлык суктырып, кыр батыры исемен алды**








## Бәйрәмгә - котлау

**Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович!**

*Сезне һәм Октябрь районы хезмәтчәннәрен Уңыш бәйрәме һәм зур хезмәт җиңүе белән чын күңелдән котлыйбыз. Сез республикада рекордлы уңыш җыюга зур өлеш керттегез. Сезгә нык сәламәтлек, барлык башлангычларыгызда уңышлар телибез.*

**Спасс район хакимияте башлыгы К.А.Нугаев.**

## *Планның чиреге тулды*

Район хуҗалыкларыннан заводка 29 мең тоннадан артыграк, ягъни планның чирегеннән күбрәк чимал керде инде. Заводның үз ярдәмче хуҗалыгы бу төр планны 75, «Кондырча» 51, «Дуслык» һәм Кузнецов исемендәге хуҗалыклар 44 - 49 процентка үтәделәр.

## Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН:

# «Кеше - уңышның төп факторы»

**Бүген безнең Октябрь районы дип исәпләнгән «урамыбызда» Норлат җирендә башланган тамырдан үзгәртеп коруларга ышанган һәм өмет белән шул юлга баскан йөзләгән, меңләгән кешеләрнең фидакарь киеренке хезмәте хөрмәтенә багышланган зур бәйрәм - уңыш бәйрәме.**

**Үзенчәлекле тарту көченә ия булган «уңыш» сүзе үз эченә ниләр ала? Безнең корреспондентыбызның халык депутатларының район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы ФАТИХ СӘҮБӘН улы СИБАГАТУЛЛИН белән әңгәмәсе шул хакта.**

***- Фатих Сәүбәнович, район кырларында күпләр өчен тормышка ашмастай тоелган мул уңыш үсте. Сез уңышның төп факторларын ничек бәялисез?***

- Әйе, быелгы елны безнең район өчен генә түгел, тулаем республика өчен зур, рекордлы уңыш елы дип бәяләргә мөмкин. Һәм аны мин уңайлы һава шартлары нәтиҗәсе итеп түгел, аерым хезмәт нәтиҗәсендә туган законлылык дип билгеләр идем. Сәбәбен аңлатам. Республикада 1992 елдан авыл хуҗалыгы товар житештерүчесенә ярдәм итү буенча Президент программасы гамәлдә һәм ул үзенең сизелерлек куанычлы җимешләрен бирә дә. Чынбарлыкта, соңгы елларда республикада кырчылык өлкәсендә зур сикереш булды.

Быел республикадагы иген игү буенча өч әйдәп баручы хуҗалык исемлегенә безнең Октябрь районы да керде. Безнең хуҗалыклар дәүләт амбарларына 86 мең тонна ашлык, шул исәптән 55 мең тонна бер дигән ашамлык бодае салдылар. Район буенча бөртекләләрнең уртача уңышы гектардан 46 центнер тәшкил итте. Билгеле, бу күрсәткечләр күктән төшмәделәр. Алар конкрет хезмәт нәтиҗәсе булып тордылар. Иң әүвәл, бу технология таләпләрен төгәл үтәү нәтиҗәсе, ягъни барлык агрочаралар да оптималь срокларда яхшы сыйфат белән үткәрелделәр. Бу эштә безгә академик Мәҗитовның киң алынлы культиваторлары алыштыргысыз булышлык иттеләр. Үзебезнең машина төзү заводында әзерләнгән 54 шундый культиватор быелгы чәчү чорында кырда кулландылар. Технология турында сөйләгәндә аркылыга - буйга чәчүнең әһәмиятен дә ассызыклап билгеләргә кирәк. Моннан тыш, кырларыбыз да кирәкле күләмдә минераль ашламалар алдылар һәм, ниһаять, үсемлекләрне корткычлардан һәм авырулардан саклау буенча киң чаралар комплексы кулланылды. Соңгысында «Агрохимсервис» «Карюэль» француз фирмасыннан алынган 22 бөркегеч агрегаттан файдаланды.

Икенчедән, инде әйткәнемчә, авылга республиканың да ярдәме зур. Менә безгә ашлама сатып алуга гына да 15 миллиард сум чамасы дотация бирелде. Быел без төрле маркадагы 90 трактор сатып алып, аларны лизинг тәртибендә (акрынлап түләү шарты белән) конкрет хуҗаларга тапшырдык. Аннары гомумән Россия Федерациясендә беренче буларак безнең кырларыбызда американың 10 «Кейс» комбайны эшләде быел. Җитештерүчәнлекләре һәм уңайлыклары буенча үзебезнекеләрдән күпкә өстен торучы ул комбайннар бөртекне дә югалтмый диярлек, эш шартлары да механизаторга үзен кеше иттереп сизәрлек. «Кейс»ларны «Агроснаб» базасында яңа төзелгән МТСның тагын 12 «ДОН - 1500», 5 «Полесье» комбайннарын һәм автотранспортны да берләштергән җыелма отрядына тапшырдык. Хуҗалык исәбендә эшләгән ул отряд иген уңышын җыюда хуҗалыкларга шактый ук саллы ярдәм күрсәтте.

Өченчедән, хуҗалыкларны реформалаштыру мәсьәләсенә уйлап якын килүне дә хәлиткеч факторлар исәбенә кертергә кирәк. Бу эштә без шаблоннан качып, үз юлыбызны, дөресрәге, югары ахыр нәтиҗәгә ирешүне төп максат иткән җиде юнәлешне сайладык.

**( Ахыры 2 биттә).**

## Җыр - моң сөюче райондашларыбыз игътибарына!

***11 октябрь көнне район мәдәният йортында сезнең өчен «Җырларым - моңнарым» дип исемләнгән концерт программасы тәкъдим ителә. Аның программасында «Татар җыры - 97» халыкара конкурс лауреаты Рәсим Низамов, Алсу Хәбибуллина җырлары, биючеләр Юлия Данилова, Ирина Мөхәммәтгәрәева чыгышлары бар. Концертны - Илсур Мортазин алып бара.***

***Ял концерты 17.00 сәгатьтә башлана, ул бушлай.***

**Концертка рәхим итегез!**

# КИЛДЕ ҖИРГӘ ШАТЛЫК БУЛЫП

## Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН:

## «Кеше - уңышның төп факторы»

*( Ахыры. Башы 1 нче биттә).*

Бу үзен аклады. Һәм, ниһаять, дүртенче, иң хәлиткеч фактор - кешеләр үзләре, аларның хезмәт сөючәнлеге, һөнәрмәнлеге, җаваплылык хисе, дип саныйм мин.

***- Районыбыз игенчеләре быел дәүләткә ашлык сату буенча килешү йөкләмәсен республикада беренче булып үтәп чыктылар, Ватан амбарларына аннан тыш та илле мең тоннадан артыграк яхшы сыйфатлы бөртек салдылар һәм шулай итеп оста игенчеләребезнең элеккеге данын яңадан кайтардылар. Фатих Сәүбәнович, уртак уңышка аеруча зур өлеш керткән хуҗалыкларны санап китсәгез иде.***

- Иң элек, реформалаштыруның беренче елында ук изге бурычны намус белән башкарып чыккан хуҗалыкларны ихлас зур рәхмәт хисләре белән әйтеп үтәсем килә. Алар арасында эреләндерелгән «Кондырча», Хафизов исемендәге, Кузнецов исемендәге, «Киекле», «Норлат» агрофирмасы составындагы «Рассвет» хуҗалыклары бар. Элеккеге «Москва», «Таң», «Заря»да оешкан кооперативлар ассоциацияләре дә безнең өметләрне акладылар, предприятиеләрнең һәм оешмаларның ярдәмче хуҗалыкларына әйләнгән «Восход» (шикәр заводы), Козлов исемендәге хуҗалык (РСУ), «Сөлчә»(«Агрохимсервис») дә әйбәт нәтиҗәләргә ирештеләр, «Родина», «Тәрнәс», «Игенче», «Заветы Ильича» һәм күп кенә башка хуҗалыклар да быел уңыш алуда сизелерлек зур алга китеш ясадылар. Бер үк вакытта хуҗалыкларга шефлык итәргә алынган предприятиеләр һәм оешмаларның да һәммәсенең ярдәме бик зур булганлыгын билгеләп үтәсем килә. Шуңа күрә дә уңыш бәйрәме - барыбыз өчен дә уртак бер бәйрәм ул. Кем әйтмешли, икмәк бар, хәзер инде җырларга да була. Һәм без анысына хаклы да, чөнки бу бәйрәмгә бөртекләрне тулысы белән җыеп алып килдек.

***- Фатих Сәүбәнович, дәүләт амбарларында ашлык артыгы белән быел, ә хуҗалыкларның үзләренә күпме соң? Аннары, крестьяннар да быелгы ашлыкка зур өмет багълыйлар бит...***

- 55 мең тонна турында әйттем инде мин. Бу - без дәүләт келәтләренә урнаштырган барлык ашамлык бодае. Шуның 50 мең тоннасы - хуҗалыкларның үз өлеше. Ул гына да түгел, әгәр сатып алучы таба алсалар, алар үз бодайларын үзләре теләгәнчә урнаштыра алалар. Крестьяннарга ашлыкны натуралата түләү тәртибендә сатып бирүдә чикләүләр булмады, хәер, аның артыгы кирәкми дә бит инде. Фуражга ашлык салуда да хуҗалыкларга мөстәкыйльлек бирелде быел. Хәзер безнең төп бурыч - халыкка «тере» акча биреп, хезмәт хакы буенча быелгы гына түгел, аннан алдагы еллардагы бурычларны да каплау. Ашлыгыбыз булгач, акчабыз да булыр дип әйтәбез.

***- Бодай игү төшемле булгач, киләсе елларда районда бу культураның мәйданнары киңәйтеләчәкме?***

- Әйе, һичшиксез. 1998 ел уңышы өчен уҗым бодаен быел арыш кадәр үк чәчеп калдырдык инде.

***- Фатих Сәүбәнович, үзегезне ирешелгән нәтиҗәләрдән тулысынча канәгать дип әйтә аласызмы?***

- Сүз дә юк, киләчәк турында уйларга кирәк. Югары гумуслы кара туфраклы Октябрь районы җирләре өчен быелгы уңыш - һич тә чик түгел әле ул. Бу җирләрдә гектардан 70 центнерга кадәр уңыш алырга була. Әнә, «Кондырча», Мичурин исемендәге хуҗалыклар быел ук гектардан 60 центнер һәм аннан да күбрәк бөртек чыгуны тәэмин итә алдылар бит. Башкаларны да шулай иттереп эшләргә күнектерергә кирәк. Киләсе елда без инде 50 центнер күрсәткечене чыгып ныгырбыз да дип ышанам. Моның өчен бөтен алшартлар бар, ә иң мөһиме, кешеләр аларның кулларыннан килмәслек эш булмаганлыгына, ахыр чиктә барысы да аларның үзләренә бәйле булуына инандылар. Шуңа да безнең уртак уңыш бәйрәмебез алдыннан барчабызга да ышаныч, оптимистлык, үҗәтлек һәм тагын... уңыш телисем килә. Ә ул теләсә нинди кыенлыкларга да карамастан яши һәм иҗат итә торган тәвәккәл һәм кыю кешеләргә генә килә. Һәркемгә дә тазалык - саулык, бәхет, гаилә бөтенлеге юлдаш булсын.

**Д.ТӘМАЕВА сөйләште.**

## Игә белгән - икмәкле

**Мичурин исемендәге хуҗалыкта 276 гектарда игелгән «Люба» сортлы сабан бодае гектарыннан 79,5 центнер чыкты.**

***

**Шул ук хуҗалыкта «Ирерия» сортлы арпа 135 гектардан 86,7шәр центнер уңыш бирде.**

***

**Мичуринлылар сабан бодаеның «Красноуфимская - 90» сортлысын 90 гектарда иккәннәр иде һәм аның уртача уңышы 67,2 центнер булды.**

***

**«Безенчук - 87» арышы «Таң» хуҗалыгында 190 гектардан 63,1әр, «Дуслык»та 61,7шәр центнер уңыш белән куандырды.**

***

**Мичурин исемендәге хуҗалыкта уҗым бодаеның «Мироновская - 808» сорты гектардан 67,2 центнер чыкты. «Кондырча»да аңардан 54,9, «Тәрнәс»тә 51,5әр центнер уңыш алдылар.**

---

***Быел район хуҗалыклары кырларындагы уңышны урып - җыюда 10 «Кейс» комбайннары эшләде. Алар көче белән барлыгы 204.995,7 центнер ашлык суктырып алынды.***

***Районда урып - җыю эшләре тәмамлангач, «Кейс»лар Бөгелмә һәм Әлки районнарына да ярдәм иттеләр. Аларның беренчесендә 20.342 центнер ашлык суктырылса, «Кейс»лар бункерыннан 18.076,2 центнер Әлки ашлыгы да бушатылды.***

## СИГЕЗЕНЧЕ ЭКИПАЖ ХУҖАЛАРЫ



**АТП**да шофер булып эшләүче Владислав кайчандыр үзе эшләгән басуларда комбайн белән игеннәрне урып - җыюда кабат катнашырмын дип, һич уйламаган иде. Чуваш Мөнҗесе мәктәбендә сигезенчедән соң ук комбайнчы ярдәмчесе булып йөрде ул. Армиядән кайткач исә мөстәкыйль рәвештә комбайн штурвалы артына утырып эшли торган булды. Авыллары тирәсендәге һәр басуны гектарына кадәр һәр участогын учындагы сызыкларыдай хәтерли, һәр карышы күңеленә якын. Язмышы аны шушы җирдән аергач та, туган туфрагы бер генә минутка да күңеленнән чыкканы булмады.

- Районга «Кейс»лар кайткан, җыелма отрядка бездән дә бер кеше сорыйлар...

АТП җитәкчелеге Булатов фамилиясенә тукталды. Тырыш, үҗәт егет. Автобуста эшләргә дә бик кирәк, әмма җыелма отряд составына да предприятие исеменә тап төшерми торган кеше булсын иде.

Җыелма отряд МТСта туплана икән. Владислав авылдашы Василий Таймуллинны да шунда очратты. Хафизов исемендәге КХАда К- 700 тракторы белән җирләрне туңга сөрүгә хәзерләнеп яткан җиреннән чакыртып алып, МТСка җибәргәннәр үзен. Элегрәк 12 еллап рәттән комбайнчы булып эшләвен истә тотканнардыр инде, мөгаен.

Якташлар шатланышып очраштылар, кул сугышып, бергә эшләргә карар кылдылар. Ни дисәң дә, бер җирдә туган, бер төбәк һавасын сулап, бер авыл әрәмәләрендә тәгәрәшеп үскән кешеләр. Аннары - бер берсенең эшкә сәләтләрен, мөмкинлекләрен дә, техникага мөнәсәбәтләрен дә әйбәт беләләр. Соңгысы америка «Кейс»ының күперчегеннән күтәрелүгә үк үзен сиздерде. Икәүләшеп «Корабның» барлык узелларын, детальләрен «капшап» чыктылар, үзебездәге «ДОН»нар, «Нива»лар белән чагыштырдылар, киңәштеләр. Комбайн никадәр камилләшкән булса да, ахыр продукцияләре ашлык бит. Ә ашлык суктыру технологиясен белгән, техниканы яраткан, аның серләрен ачарга омтылышы көчле булган кеше өчен аның теләсә нинди төрлесе, маркалысы үзләштерерлек.

Булатов Таймуллин составындагы сигезенче номерлы экипаж беренче бункер ашлыкны гадәти комбайннардан шактый соңлап - 8 август көнне бирде. Егетләрдә исә яңа төр техниканы тизрәк үзләштерү, аны югары җитештерүчән файдалану теләге шулкадәр көчле иде ки, хәтта төшке ял, кичке караңгы белән дә исәпләшмичә эшләргә туры килде. «Киекле», «Правда», «Таң», «Родина», «Рассвет» ассоциацияләрендә, шикәр заводы һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыклары басуларында һ.б., гомумән, ай ярымлык вакыт эчендә үзебезнең район кырларындагы уңышны тулысынча җыйнап, Бөгелмә районы кырларында эшләргә туры килде. «Кейс» комбайнчылары бер - берсенең нәтиҗәләре белән даими кызыксынып тордылар. Әле бер агрегат беренче урынга чыкты, әле икенчесенең суктырылган центнерлары күбәйде.

- Кайда эшләсәк тә, хуҗалыкны да, басуларны да, авыл кешеләрен дә үзебезнеке белән чагыштыра идек. Безнең Хафизов исемендәге хуҗалыкта эш тә күпкә оешкан, җирләре дә тигез, кешеләре дә тырыш диген нәтиҗәгә килдек,- диләр егетләр - югыйсә, без эшләгән һәр җирдә дә үзебезне колач җәеп каршы алалар иде...

Туган җирнең кадерле, күңелгә газиз булуы табигый нәрсә инде. Шул ук вакытта Владислав белән Василий үзләренең яшьли үзләштергән һөнәрләренең йөрәкләрендә калуын тагын бер кат аңладылар. «Кейс»лар арасында иң күп ашлык суктыручылары да шул хакта сөйли.

- Отрядыбыз җыелма булса да без, гомер буе бер коллектив әгъзаларыдай иңгә - иң торып эшләдек,- диделәр безгә сигезенче экипаж егетләре - яңа техника серләрен дә бергәләп өйрәндек.

Киләчәктә дә басуда эшләргә теләкләре булуы, кодрәтле «Кейс»лар, дуслык, хезмәттәшлек турында озак сөйләштек без егетләр белән. Һәр сүзләре, һәр фикерләре, киләчәккә булган ниятләре җир хуҗаларыныкыдай төпле, дәлилле иде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## АЛАРНЫҢ ДА ӨЛЕШЕ БАР

«Агрохимсервис» ачык типтагы акционерлык җәмгыяте коллективы соңгы елларда район кырларының уңдырышлылыгын күтәрүгә юнәлдерелгән максатчан программаны уңышлы гамәлгә ашыра. Быел гына да алар көче белән районыбыз кырларына 102 мең тонна органик ашлама чыгарылды. 4.900 гектарга минераль ашлама кертелде. Җәмгыять көче белән районыбыз хуҗалыкларының ачы туфраклы 3.950 гектары известьланды. 49 мең гектарда үсемлекләрне химик саклау үткәрелде.

Гомуми уңышка механикалаштырылган отрядтан А.Убамзаров аеруча зур өлеш кертте. Т - 150 тракторы белән ул быелның 9 аенда 3512 шартлы эталон - гектарда эш башкарды.

Химияләштерү отрядыннан Ә.Әхмәдиевның да хезмәт күрсәткечләре күркәм. Быел ЛТЗ - 55 тракторы белән 6.067 гектарда эш башкарды.

**Л.Петрова.**

## Тырыш хезмәт- мул уңыш



**Уҗым бодаеның «Харьков - 92» сорты «Таң»да 130 гектардан 57,8әр, «Родина»да 120 гектардан 52,7шәр центнер уңыш бирде.**

***

**Кузнецов исемендәге хуҗалыкта сабан бодаеның «Энита» сорты 260 гектардан 53,8әр, «Симбирка» сорты 336 гектардан 54,7шәр центнер уңыш белән куандырды.**

# TV

**ПОНЕДЕЛЬНИК, 13 ОКТЯБРЯ**

**ОРТ**

6.00 «Доброе утро»
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 1.15 Новости
9.15, 18.20 «Девушка по имени Судьба»
10.00 Поле чудес
10.55 Здоровье
11.20 Домашняя библиотека
11.30, 19.35 «Угадай мелодию»
12.15 «Особенности национальной охоты»
14.10 «Огонь»
14.25 Футбольное обозрение
15.20 «Драконы подземелий»
15.45 Марафон - 15
16.05 Звездный час
16.40 «Космическая полиция»
17.05 ...До шестнадцати и старше
17.30 «Сто лет приключений»
19.10 Час пик
20.00 «Человек в маске»
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время
21.45 «Полтергейст-2»
22.40 «Театр+ТВ»
23.25 «Линия кино». «Мечты идиота»

**РТР**

7.10 Мультфильм
7.35 «Медицина для вас»
7.40 Вовремя
7.45 Монетный двор
8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 Вести
8.20 Дежурная часть
8.35 «Итальянский ресторан»
9.35, 18.40"История одного события»
9.50, 10,50, 1.00 Товары - почтой
10.00, 17.25 «Санта-Барбара»
11.20 L-клуб
11.50 Совершенно секретно
12.45 Свой дом
12.55 Сам себе режиссер
13.25 Парламентский вестник
13.55 Магазин недвижимости
14.20 Деловой автограф
14.25, 16.20 Лучше не бывает
14.30 «Золото Неаполя»
16.10 Графоман
16.25 Эксповестник
16.30 На пороге века
17.20 Православный календарь
18.15, 0.55 Прогноз погоды
18.20 Лукоморье
18.55 «Итальянский ресторан»
20.35 Национальный интерес
21.05 «Под прицелом»
22.45 Программа передач
22.50 Мой Пушкин
23.15 Вовремя
23.25 Добрый вечер
0.10 Дежурная часть
0.25 Лестница в небо

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 «Чулпан»
17.30 Мультфильм
17.50 Балалар өчен «Тамчы»
18.05 «Бизнес TV»
18.45, 20.45«Җиһан». Хәбәрләр
19.05 «Замандаш» цыклыннан «Җан җылысы». Әхмәт Гадел
19.45 Новости
20.00 «Ирек»
20.30«Әлли-бәлли-бәү»
21.00 «Эскадрон гусар летучих»
22.25 «Карт-бланш»

**ВТОРНИК, 14 ОКТЯБРЯ**

**ОРТ**

6.00 «Доброе утро»
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 1.15 Новости
9.15, 18.20 «Девушка по имени Судьба»
10.00 «Человек в маске»
10.40 «Смехопанорама»
11.20 Домашняя библиотека
11.30, 19.35 «Угадай мелодию»
12.15 «Следствие ведут знатоки»
13.30 «Колесо истории»
14.15 «Театр+ТВ»
15.20 «Драконы подземелий»
15.45 Кварьете «Веселая квампания»
15.55 Счастливый случай
16.40 «Космическая полиция»
17.05 ...До шестнадцати и старше
17.30 «100 лет приключений»
19.00 Футбол. Чемпионат России
21.00 Время
21.45 «Долорес Клейборн»
0.10 Хоккей
1.50 «Отряд «Глория»

**РТР**

7.10 Мультфильм
7.35 «Стронг»
7.40 Вовремя
7.45 Монетный двор
8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 Вести
8.20 Дежурная часть
8.35, 18.35 «Итальянский ресторан»
9.35, 18.40 «История одного события»
9.50, 10.50 Товары-почтой
10.00, 17.25 «Санта-Барбара»
11.20, 11.40 Национальный интерес
13.25 Пульс
13.55 Магазин недвижимости
14.20 Деловой автограф
14.25 Регион Кузбасса
14.30 «Нулевой вариант»
16.05 «Светлячок»
16.10 Графоман
16.20 Лучше не бывает
16.25 Эксповестник
16.30 Новое пятое колесо
17.20 Православный календарь
18.15 Прогноз погоды
18.20 Лукоморье
20.30 Реклама
20.35 Национальный интерес
21.10 «Осень»
22.50 Мой Пушкин
23.15 Вовремя
23.25 Добрый вечер
0.10 Дежурная часть
0.25 Горячая десятка
1.25 Товары-почтой

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 «Чулпан»
18.05 Мультфильм
18.25 «Слово депутата»
18.45, 20.45 «Җиһан». Хәбәрләр
19.00 Программа телестудий республики
19.20 «Клуб Болл»
19.45 Новости
20.00 «Карт-бланш»
20.30«Әлли-бәлли-бәү»
21.00 «Эскадрон гусар летучих»
22.35 «Вертуальные впечатления»

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Кадерле тормыш иптәшем, әтиебез **Илсөяр Мәхмүт улы Сөләймановка** 45 яшь тула. Аны туган көне белән чын йөрәктән кайнар котлап, таза исәнлек, бәхет, иминлек, җан тынычлыгы, озын гомер телибез.*

***Хатыны, балалары.***



# Белдерүләр

## САТАБЫЗ

**Йорт өчен 5 х 11 метрлы бура**
. Адрес: Завод тыкрыгы, 2 - 16, 17 сәг.тән соң.

**

**1992нче елгы «Москвич - 2141», 18 мең км. юл үткән.** Тел.: 5 - 38 - 34.

***

**Мутон тун, яңа. Бәясе 3 млн. 800 мең сум.** Тел.: 5 - 25 - 50.

***

**Шикәр заводы районында 2 бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 28 - 05, 18 сәг.тән 19 сәг.кә кадәр.

***

**Ашыгыч рәвештә стенка, йорт сатыла яки ике бүлмәле фатирга алыштырыла**. Адрес: Маяковский ур., 58.

***

**Яңа йортта әйбәт планировкалы ике бүлмәле фатир, зур лоджиясе бар.** Адрес: Толстой ур., 8.

***

**Чистарту корылмалары янында дача участогы.** Адрес: Советская ур., 183 - 112, бәясе - килешү буенча.

***

**Йорт өчен 8 х 10 метрлы бура**. Адрес: Школьная ур., 4 - 5, шимбә, якшәмбе көннәрендә.

***

**Бер бүлмәле фатир**. Адрес: 60 лет Октября, 19 - 14. 12дән 15 сәг.кә кадәр.

***

**«Алмалык»та бакча участогы.** Адрес: Козлов ур., 12 - 19.

***

**Чистарту корылмалары районында ике гараж, тимер юл поселогында дача**. Арадашчы тел.: 5 - 27 - 72 (кич белән).

***

**1993 нче елгы ВАЗ - 2193, бәясе килешү буенча.** Тел.: 2 - 15 - 59.

***

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Свердловск өлкәсе Азбест шәһәрендә 4 каттагы 1 бүлмәле фатирны - Норлаттагы шундый укка. Татарстанның башка шәһәрләренә дә мөмкин.** Тел.: 5 - 16 - 91.

***

**Кормыш поселогында ике бүлмәле фатир ике берәр бүлмәлегә, вариантлар мөмкин.** Тел.: 5 - 21 - 45.

***

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Кызыл - ак төстәге сыер югалды. Арканында ак сыр, маңгаенда ак тап, 7 яшь.** Күрүчеләрне Аксумла авылына Игнатьевка хәбәр бирүләрен сорыйбыз.

**Арзан һәм сыйфатлы итеп гаражлар, йортлар төзибез.** Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗип.

**Норлат җирле үзидарә Советы карары нигезендә 12 нче октябрь көнне Уңыш - 97 бәйрәмендә сәүдә итүчеләргә түбәндәге җыемнар билгеләнде: предприятие, оешма, коммерция предприятиеләре, крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциацияләре өчен - 30 мең сум, шәхси затлар өчен - 15 мең сум. Акча җыю МПП ЖКХсына тапшырылган. Җыелган керемнәр шәһәрне төзекләндерүгә кулланылачак.**

Җирле үзидарә Советы.



# ГАИ рейдта

Соңгы вакытта шәһәрдә автомашиналардан запас частьләр урлау фактлары ешайды. Зыян күрүчеләрнең хәлен аңлау авыр түгел. Ни өчен дигәндә җинаятьчеләр нигездә иң дефицит запас частьләрне (тәрәзә, машина резинасы, аккумуляторлар) урлыйлар, ә базарда әлеге запас частьләргә бәяләр көннән - көн арта һәм аларны сатып алу өчен һәркемнең дә кесәсе мөмкинлек бирми.

Бу шартларда гаражларның техник торышын ныгыту зарури. Мөмкин булганда хәтта инструментлар ярдәмендә ачылмый торган эчке йозаклар куярга кирәк. Автомашина озак басып торганда аның көпчәген салдырырга, бензинын агызып алырга, аккумуляторын ычкындырырга кирәк. Пыялаларга маркировка үткәрсәң дә ярый. Көпчәкләргә шпилькалар ясау да тәкъдим ителә, аларны бары тик индивидуаль ачкыч ярдәмендә борып алып булачак.

Караклар иртәме- соңмы барыбер тотылып җаваплылыкка тартылачаклар. Әмма сафтан чыгарылган транспортны аякка бастыру җиңел нәрсә түгел.

Шул ук вакытта мондый очраклар еш кына транспорт хуҗаларының гаепләре буенча барлыкка килүе белән килешми мөмкин түгел. Кайберәүләр еш кына ачкычларын машинада калдыралар, транспортларын гаражга кертү чарасын күрмиләр. Ә җиңел тормыш эзләүчеләргә шул гына кирәк тә.

Эчке эшләр бүлеге автомашиналарның запас частьлар урлауны кисәтү максатында рейдлар үткәрә, автомашиналар һәм мотоцикларын гаражларда сакламаган кешеләрнең техникалары штраф тукталышына куелачак.

Хөрмәтле шоферлар! Сезне алда санап кителгән киңәшләрне тотарга чакырабыз. Сез шулай итеп үз транспортыгызны гына саклап калмыйча җинаятьне дә кисәтәчәксез.

**Х.ӘЮПОВ,**
**ГАИ начальнигы,**
**милиция майоры.**

## *«Уңыш - 97» бәйрәмендә тотали - заторда уйнау кагыйдәләре*

*1. Уен «икеләтә экспресс» методы буенча үткәрелә, ягъни уенда катнашучы заездда 1 һәм 2 урынны алучы атлар номерын белергә тиеш.*

*2. Ставканы теләсә кайсы заездда куярга мөмкин. Заезд башлангач әлеге заездга ставкалар кую тәмамлана.*

*3. Уенда катнашу бәясе 5 мең сум.*

*4. Кассир катнашучыга ул үзе атаган җиңүчеләр номерлары күрсәтелгән чек бирә.*

*5. Отышны түләүгә әлеге заездан кергән керемнең 75 проценты юнәлтелә. Призлы фонд I - II- урыннарны алучыларны дөрес билгеләгән катнашучылар арасында тигез бүленә.*

*6. Әгәр заездда җиңүчеләрне беркем дә дөрес атамаса приз фонды киләсе заездга калдырыла.*

*7. Отышларны түләү чек нигезендә шуннан соңгы заездлар вакытында башкарыла.*

***Оештыру комитеты.***

# Хәлле гражданнар өчен!

## *Саклык банкында яңа «Юбилейный» вклады.*

**Башлангыч взносның минималь суммасы 20 млн. сум. Кертемнең саклану вакыты - өч ай да бер көн.**

**- Килешү нигезендә кертемне саклау вакытында гамәлдәге процент ставкасы.**

**- Һәр айда процентларны исәпләп бару.**

**- Керем, чыгым операцияләре башкару мөмкинлеге.**

**- Өстәмә взнос размеры 10 млн. сумнан да ким түгел.**

**- Чыгым операциясе башкарганнан соң кертемнең калдыгы - 20 млн.нан да ким калмаска тиеш.**

**- Вкладчы килмәгән очракта да килешүне берничә тапкыр озайту мөмкинлеге.**

**Процент ставкасы пролонгация көненә Татарстан Саклык Банкы учреждениеләрендә гамәлдәге ставка санала. Сезне район Саклык банкы бүлекчәсе филиалларында көтәбез.**

Өстәмә информацияне 2 - 25 - 83, 2 - 22 - 36, 2 - 24 - 55, 2 - 25 - 88, 2 - 21 - 21 телефоннары аша алырга мөмкин.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.